СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район,
422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа
авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советы карары**

**« 01 » июль 2024г** **№ 103**

**«Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм Наласа авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында» 2024 елның 04 июньдәге 101 номерлы Наласа авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасында Муниципаль хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 06 майдагы 300 номерлы карары белән,Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге уставы нигезендә, Наласа авыл җирлеге Советы карар бирде:

2. «Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм Наласа авыл җирлегенең аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм шартлары турында»2024 елның 04 июньдәге 101 номерлы Наласа авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 Пункт Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга хезмәт хакы түләү турында Нигезләмәне (2 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Наласа авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең вазыйфаи окладына күләмен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициенты түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Коэффициент |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе | 1,37 |
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) | 1,33 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,11 |
| 1 категорияле белгеч<br>2 категорияле белгеч<br>белгеч | 1,00 |

3. Әлеге карар 2024 елның 01 июленнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) Җирлекләр бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Наласа авыл җирлеге башлыгы:** **И.Р.Шакирова**